**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 ноябрендәге 4869 номерлы карары**

**Казан шәһәре Идел буе районының Хөсәен Мәүлүтев урамында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 20729 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:160201:3;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары: 16:50:160201, 16:50:160202, 16:50:160203, 16:50:160205;
- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 2 ел;

1.2. гариза бирүче: «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тотуның һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче гаризасы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, «Казан шәһәренең Мәүлүтев урамында җир асты җәяүлеләр кичүе төзелеше» объектына проект документлары (2020 елның 12 октябрендәге М-72 номерлы техник бирем).

2. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 26 ноябрендәге
4869 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Идел буе районының Хөсәен Мәүлүтев урамында ачык сервитут чикләре**



Масштаб 1:5000

Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 1 | - яңа ясалган характерлы нокта; |
| | - билгеләнә торган сервитут чиге; |
| | - кадастр кварталы чиге; |
| | - гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге; |
| | - кызыл линия; |
| 16:50:160201, 16:50:160202, 16:50:160203, 16:50:160205 | - кадастр кварталы; |
| 16:50:160201:3 | - хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | - капиталь төзелеш (линия) объектлары |

______________________________